**СОВЕТ КИРБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422626 с. Кирби,
ул. Горького, д.26а
тел:   4-38-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХӘЕРБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422626 Хәерби авылы,
Горкий урамы, 26а нчы йорт,
тел:    4-38-16

**2022елның «21» ноябре** **14 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегендә Хәерби торак пункты гражданнары җыены карары.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегенең Хәерби торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Лаеш муниципаль районының Хәерби торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән( балачактан көндезге формада белем алучы һәм инвалидларны исәпкә алган студентлардан тыш) 2023 елда үзара салым акчаларын 1000 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Хәерби торак пунктында Гәрәй ур., Гвардия ур., Пионер ур., Сельсовет ур., Мәктәп ур., Молодежная ур., Юность урамнарында урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту( сатып алу, күчереп йөртү, вак таш һәм ком салу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, техник күзәтчелек өчен түләү)

- Хәерби торак пунктының иске зиратын төзекләндерүгә (агачларны кисү, территорияне чүп-чардан арындыру, ташу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)»

3. Әлеге карарны Хәерби авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында һәм Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________________ Р.К.Зинәтуллин**

**Башлык-Хәерби авыл җирлеге**
**Советы рәисе: _________________ Р.К.Зинәтуллин**